СОВЕТ
ТУКАЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТУКАЙ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

пр. М. Джалиля, 46, г. Набережные Челны, 423800

М. Җәлил пр., 46, Яр Чаллы шәһәре, 423800

Телефон/факс (8552) 70-37-82, tukay@tatar.ru

29.08.2025 № 61/5

На №__________ от______________

# КАРАР

2022 елның 21 мартындагы 19/11 номерлы «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районында гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында нигезләмә»гә үзгәрешләр раслау хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләре турында» 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы уставы нигезендә муниципаль берәмлек Советы

## КАРАР БИРДЕ:

1. Тукай муниципаль районы Советының 2022 елның 21 мартындагы 19/11 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районында гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында нигезләмә»гә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Түбәндәге эчтәлектәге 15 бүлекне өстәргә:

«15. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Советына кергән гражданнар мөрәҗәгатьләренә анализ ясау тәртибе

15.1. Һәр яртыеллык йомгаклары буенча Советның гомуми бүлеге баш белгече гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләрне гомумиләштерә.

15.2. Гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләрне анализлау нәтиҗәсендә елга ике мәртәбә аналитик белешмә төзелә, ул кергән, каралган язма мөрәҗәгатьләр, электрон документ формасындагы мөрәҗәгатьләр саны, шәхси кабул итүдә, чыгып шәхси кабул итүдә кабул ителгән гражданнар саны, мөрәҗәгатьләрнең тематикасы, мөрәҗәгатьләрне карау нәтиҗәләре буенча күрелгән чаралар турында мәгълүмат булган, узган ел белән чагыштырылган гражданнарның мөрәҗәгатьләренә (телдән һәм язмача) чагыштырма анализны үз эченә алырга тиеш.

15.3. Аналитик белешмә Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Советының гомуми бүлеге баш белгече тарафыннан җиде эш көне эчендә Тукай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырыла.».

2. Әлеге карарны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Тукай муниципаль районы мәгълүмат сайтында (https://tukay.tatarstan.ru/) урнаштырырга.

3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Муниципаль берәмлек Башлыгы
вазифаларын башкаручы,
Совет Рәисе урынбасары Р.И. Закиров